АГЕНТСТВО
ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ
АГЕНТЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**« _15_ » июля 2013 г.** № 102/2лс

Казан ш.

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурс турында**

2004 елның 27 июлендәге “Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында”гы ФЗ-79 номерлы Федераль закон, РФ Президентының 2005 елның 1 февралендәге “Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурс турында”гы 112 номерлы Указы, 2003 елның 16 гыйнварындагы “Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәте турында”гы ТРЗ-3 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

БОЕРАМ:

1. Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясенең эш тәртибен һәм вакытларын расларга (1 нче номерлы кушымта).

2. Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурс үткәрүнең методикасын расларга (2 нче номерлы кушымта).

3. Татарстан Республикасы Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү комитетының 2009 елның 29 июнендәге “Дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурс турында”гы 30 нчы номерлы боерыгы көчен югалткан дип табарга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Якупов Л.Г.

Татарстан Республикасы
Инвестицион үсеш агентлыгының
2013 елның 15 июлендәге
102/2лс номерлы карары белән
расланган
1 нче номерлы Кушымта

**Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясенең эш тәртибе һәм вакытлары**

1. Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгында (алга таба - Агентлык) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясе (алга таба – конкурс комиссиясе) үз эшчәнлеген даими нигездә тормышка ашыра һәм рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия вәкилләреннән гыйбарәт.

2. Конкурс комиссиясе белән җитәкчелек итү конкурс комиссиясенең рәисе тарафыннан башкарыла. Конкурс комиссиясе рәисе вакытлыча эштә булмаганда (авыру, командировкага китү, отпуск ялында булу h.б.) конкурс комиссиясе белән конкурс комиссиясе рәисе урынбасары җитәкчелек итә.

3. Конкурс комиссиясенең эшен тәэмин итүне (гаризаларны теркәү һәм кабул итү, эшләрне формалаштыру h.б.), конкурс комиссиясе утырышында беркетмә тутыруны Агентлыкның кадр эшчәнлеген алып бару буенча җаваплы хезмәткәре – конкурс комиссиясе сәркатибе башкара. Конкурс комиссиясенең сәркатибе Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаны (алга таба – дәүләт хезмәтенең вакант вазыйфасы) биләү буенча конкурста катнашучы кандидатларны бәяләүдә катнаша һәм конкурс комиссиясе карар кабул иткәндә тавыш бирү хокукына ия.

4. Конкурс комиссиясенең утырышы Агентлык җитәкчесе тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаны биләү буенча конкурс (алага таба - конкурс) игълан ителү һәм үткәрелү турында боерык фәрман ителгәндә уздырыла.

5. Конкурс комиссиясенең утырышы анда катнашучы граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына дәгъва кылучы кандидатлар икедән дә ким булмаганда уздырыла.

Конкурс комиссиясенең утырышы анда барлык әгъзаларның өчтән ике өлешеннән дә ким булмаган күләмдә катнашканда законлы дип санала. Конкурс комиссиясен бары тик аның әгъзалары – граждан хезмәте вазыйфаларын биләүчеләр катнашында гына уздыру рөхсәт ителми.

6. Конкурсны үткәргән вакытта конкурс комиссиясе, граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына карата булган квалификацион таләпләрдән һәм әлеге вазыйфа буенча башка вәкаләт регламенты нигезләмәләреннән, шулай ук Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турындагы законнары тарафыннан каралган башка нигезләмәләрдән чыгып, дәгъва кылучыларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын бәяли һәм конкурсның җиңүчесе турында карар кабул итә.

7. Конкурс комиссиясенең конкурс нәтиҗәләре буенча карары утырышта катнашкан әгъзаларының ачык рәвештә биргән тавышларының гади күпчелеге белән кабул ителә.

Тавышлар тигез булганда, конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч санала.

8. Конкурс комиссиясенең карары граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына дәгъва кылучы кандидаттан тыш кабул ителә һәм аны граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына билгеләргә яисә мондый билгеләүдән баш тартуга нигез булып санала.

9. Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре утырышта катнашкан рәис, рәиснең урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзалары тарафыннан имзаланган карар белән рәсмиләштерелә.

10. Граждан хезмәтендәге вакант вазыйфага дәгъва кылучы кандидат конкурс комиссиясенең карарын Россия Федерациясе законнары нигезендә кире караттырырга хокуклы.

Татарстан Республикасы
Инвестицион үсеш агентлыгының
2013 елның 15 июлендәге
102/2лс номерлы карары белән
расланган
2 нче номерлы Кушымта

**Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурс үткәрүнең методикасы**

## Гомуми кагыйдәләр

1. Граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурс үткәрүнең әлеге методикасы (алга таба – методика) Агентлыкта конкурс оештыруның һәм үткәрүнең тәртибен ачыклый.

2. Конкурсны үткәрүнең төп бурычлары булып түбәндәгеләр санала:

– граждан хезмәтенә дәгъва кылу буенча тигезлек булдыруда Россия Федерация гражданнарының конституция хокукларын саклауны тәэмин итү,

– конкурс нигезендә вазыйфаи үстерүдә дәүләт граждан хезмәткәрләренең хокукын саклау.

3. Конкурс граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына дәгъва кылучы кандидатларның профессиональ дәрәҗәсен, аларның әлеге вазыйфага карата булган квалицикацион таләпләргә туры килүен бәяләүдән һәм җиңүчене ачыклаудан гыйбарәт.

## Конкурсны үткәрүне оештыру

4. Конкурс Агентлык җитәкчесе карары белән, граждан хезмәтендә вакант

(граждан хезмәткәре белән биләнмәгән) вазыйфа булганда, әлеге вазыйфаны биләү 2004 елның 27 июлендәге “Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында”гы ФЗ-79 номерлы Федераль законның 22 статьясы нигезендә конкурс шартларында мөмкин булганда игълан ителә һәм Агентлык боерыгы белән рәсмиләштерелә.

5. Конкурс ике этапта үткәрелә. Беренче этапта, Идарә кадрларының федераль порталы сервисындагы Агентлыкның рәсми сайтында конкурста катнашу буенча документлар кабул ителү турында игълан урнаштырыла, шулай ук конкурс турында түбәндәге мәгълүматлар: граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаның исеме, әлеге вазыфага дәгъва кылучыга карата булган таләпләр, граждан хезмәтен үтүнең шартлары, конкурста катнашу өчен кирәкле документларның исемлеге, аларны кабул итүнең урыны һәм вакыты, әлеге документларны кабул итүнең тәмамлану вакыты, конкурсны үткәрүнең ниятләнгән көне, урыны һәм аны үткәрүнең тәртибе.

6. Конкурста катнашырга теләк белдерүче гражданин дәүләт органына түбәндәгеләрне тапшыра:

а) шәхси гариза;

б) формасы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган, үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета, фотосурәтен теркәү белән берлектә;

в) паспортның яисә аны алыштыручы документның (тиешле документ конкурска шәхсән килгәндә күрсәтелә) күчермәсе;

г) кирәкле профессиональ белемне, эш стажын һәм квалификацияне раслый торган документлар:

хезмәт кенәгәсенең (хезмәт (вазыйфа башкару) эшчәнлеге беренче тапкыр тормышка ашырылган очраклардан тыш) яисә гражданинның хезмәт (вазыйфа башкару) эшчәнлеген раслый торган башка документларның күчермәсе;

профессиональ белем алу турындагы документларның, шулай ук гражданинның шәхси теләге буенча – өстәмә профессиональ белем алу турындагы, гыйльми исемнәре турындагы документларының нотариаль яктан яисә хезмәт (вазыйфа башкару) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан рәсмиләштерелегән күчермәләре;

д) гражданинның граждан хезмәтенә куелуына һәм үтүенә комачау итүче

чирләре булмавы турында документ;

е) 2004 елның 27 июлендәге “Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында”гы ФЗ-79 номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте боерыкларында каралган башка документлар.

7. Агентлык хезмәткәре булган граждан хезмәткәре гаризаны җитәкче исеменә тапшыра.

Башка дәүләт органындагы конкурста катнашырга теләк белдергән Агентлыкның граждан хезмәткәре әлеге дәүләт органына эшкә алучы вәкиле исеменә гариза һәм үз кулы белән тутырып һәм имзалап, Агентлыкның кадр эшчәнлеген алып бару буенча җаваплы хезмәткәре тарафыннан рәсмиләштереп, фотосурәте белән берлектә, анкетасын тапшыра.

8. Методиканың 6, 7 пунктларында күрсәтелгән документлар Агентлыкка аларны кабул итүне игълан иткән көннән башлап 21 көн эчендә тапшырыла.

Нигезле сәбәпләрсез документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә яисә рәсмиләштерүдә төгәлсезлекләр җибәреп тапшыру гражданиннан аларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

Нигезле сәбәпләр булганда, эшкә алучының вәкиле (конкурс комиссиясенең рәисе) аларны кабул итүнең вакытын күчерә ала.

9. Гражданинның (граждан хезмәткәренең) рөхсәте белән, аңа дәүләт яисә закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүматларны, әгәр дә гражданин (граждан хезмәткәре) дәгъва кылучы граждан хезмәтенең вәкаләтле вазыйфаларын башкару мондый мәгълүматларны куллану белән бәйле булса, рөхсәт итүне рәсмиләштерү процедурасы үткәрелә.

Гражданин тарафыннан җитәкче исеменә тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге тикшерелүгә дучар ителә.

Граждан хезмәткәре тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның дөреслеген тикшерү бары тик ул граждан хезмәтенең югары төркемендәге вазыйфаларына караучы граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләү буенча конкурста катнашкан очракта гына башкарыла.

10. Граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына булган квалификацион

таләпләргә туры килмәгәндә, шулай ук Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турындагы законнарында граждан хезмәтенә алыну һәм аны үтү буенча каралган чикләүләр нигезендә, гражданин (граждан хезмәткәре) конкурска кертелми.

11. Конкурсның икенче этабын үткәрүнең көне, урыны һәм вакыты турындагы карар конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан граждан хезмәтендәге вакант вазыйфага дәгъва кылучылар тапшырган мәгълүматларның дөреслеген тикшергәннән соң, шулай ук кирәк булганда дәүләт яисә закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүматларга рөхсәт алу рәсмиләштерелгәннән соң кабул ителә.

12. Тикшерү барышында федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка хокукый актлары тарафыннан гражданинның граждан хезмәтенә алынуына комачау итүче яклары ачыкланган очракта, конкурс комиссиясенең сәркатибе аңа конкурста катнаша алмавының сәбәпләрен җиткерә.

13. Граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаны биләү буенча конкурста катнашу мөмкинлегеннән мәхрүм ителүче әлеге карарны Россия Федерациясе законнары нигезендә кире каратырга хокуклы.

14. Конкурста катнашырга рөхсәт алучы гражданнарга (граждан хезмәткәрләренә) (алга таба - кандидатларга), конкурсның икенче этабы башланырга 15 көннән дә соңармыйча, конкурс комиссиясенең сәркатибе аның кайсы көнне, кайда һәм нинди вакытта үткәрелүе турында хәбәр итә.

15. Әгәр дә конкурс үткәрү барышында, аңа дәгъва кылу буенча игълан ителгән граждан хезмәтенең вакант вазыйфасының квалификацион таләпләренә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаса, Агентлыкның җитәкчесе конкурсны кабат үткәрү карарын кабул итә ала.

16. Конкурсның икенче этабында конкурс комиссиясе кандидатларны, алар тарафыннан тапшырылган алган белеме, граждан яки башка дәүләт хезмәтен үтүе, башка хезмәт эшчәнлеген башкаруы турындагы документлар, шулай ук федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килми торган конкурс процедуралары (аерым сөйләшү, анкета сорауларына җавап бирү, төркем дискуссияләрен үткәрү, реферат язу яисә граждан хезмәтенең вакант

вазыйфасындагы бурычларны үтәү белән бәйле булган вәкаләт бурычларына кагылышлы сораулар буенча тест үткәрү) нигезендә профессиональ һәм шәхси сыйфатларын бәяли һәм конкурсның җиңүчесе турында карар кабул итә.

17. Конкурсны үткәрү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясенең карарлары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы әгъзалары биргән тавышларның гади күпчелеге нигезендә, кандидаттан башка кабул ителә.

18. Конкурс комиссиясенең карары кандидатны граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына куелуына яисә мондый карарны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

## Соңгы кагыйдәләр

19. Конкурс нәтиҗәләре буенча граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына конкурсның җиңүчесен билгеләү турында Агентлык боерыгы чыгарыла һәм конкурсның җиңүчесе белән хезмәт килешүе төзелә.

20. Конкурс тәмамланганнан соң 7 көн эчендә конкурс комиссиясенең сәркатибе кандидатларга аның нәтиҗәләре турында хәбәр итә. Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат шулай ук билгеләнгән вакытка Агентлыкның рәсми сайтына урнаштырыла.

21. Граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына дәгъва кылып, конкурска кертелмәгән кандидатларның документлары һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары конкурс тәмамланганнан соң өч ел эчендә язмача гариза буенча кире кайтарылырга мөмкин. Бу вакыт узганчыга кадәр документлар Агентлыкның архивында саклана, аннан соң юк ителүгә дучар була.

22. Кандидат конкурс комиссиясенең карарын Россия Федерациясе законнары нигезендә кире караттырырга хокуклы.